РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
КОШКИ-ШЕМЯКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШӘМӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

03 ноябрь 2021ел № 32-1

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Шәмәк авыл җирлеге
составына керүче торак пунктларда
гражданнар җыенын уздыруга әзерлек
тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр
кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясын гамәлгә ашыру максатларында Буа муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге Советының 2018 елның 3 сентябрендәге 51-3 номерлы карары (21.05.2020 ел, № 80-1 карар редакциясендә) белән расланган «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын уздыруга әзерлек тәртибе турында нигезләмә»гә (алга таба-Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Нигезләмә тексты:

киләсе редакциядә 1.6.1 пунктын өстәргә:

«1.6.1. Гражданнар җыены авыл җирлеге составына керүче торак пункт территориясе өлешендә торак пунктның әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелергә мөмкин.

Мондый гражданнар җыены Буа муниципаль районының Шәмәк авыл җирлеге Советы тарафыннан, 10 кешедән дә ким булмаган торак пункт территориясенең тиешле өлешендә яшәүчеләр инициативасы белән оештырыла.

Буа муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге Советы карары белән, гражданнар җыены үткәрелә торган торак пункт территориясе чикләре, торак пункт территориясенең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүдәге гомуми мәнфәгатьләр критерийларыннан чыгып билгеләнә..»;

1.2. 3.5 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3.5. Гражданнар җыены сайлау хокукына ия торак пунктта яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы (яисә аның территориясенең бер өлеше) яисә җирлектә яшәүчеләр катнашында хокуклы. Кворум булмаганда, гражданнар җыенын үткәрүнең яңа датасын билгеләү муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан башкарыла. Бу очракта гражданнар җыены гражданнар җыенын үткәрү билгеләнгән көннән соң ун көннән дә соңга калмыйча үткәрелергә тиеш».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Шәмәк авыл җирлеге
башлыгы, Татарстан Республикасы Буа
муниципаль районы Шәмәк авыл
җирлеге Советы рәисе И.Н. Никитина